СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

11.12.2024 № 52/4

На №__________ от______________

# КАРАР

## 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар планы чорына Тукай муниципаль районы бюджеты турында

1 статья

1. 2025 елга Тукай муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Тукай муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразланган гомуми күләме 1 653 762,29 мең сум;

2) Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының фаразланган гомуми күләме 1 653 762,29 мең сум;

3) Тукай муниципаль районы бюджеты дефициты 0 сум.

2. 2026 елга һәм 2027 елга Тукай муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) 2026 елга Тукай муниципаль районы бюджет керемнәренең гомуми күләме 1 747 283,24 мең сум, 2027 елга 1 857 806,68 мең сум;

2) Тукай муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен расларга:

- 2026 елга 1 747 283,24 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 18 815,12 мең сум;

- 2027 елга 1 857 806,68 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 39 630,34 мең сум;

3) 2026-2027 елларга Тукай муниципаль районы бюджеты дефицитын 0 кыйммәте белән.

3. Тукай муниципаль районы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 1 кушымта нигезендә;

- 2026 һәм 2027 еллар планы чорына әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.

2 статья

1. 2026 елның 1 январена Тукай муниципаль районының муниципаль эчке бурычы югары чиген нуль зурлыгы белән, шул исәптән муниципаль гарантияләр

буенча эчке бурычның югары чиген нуль зурлыгы белән расларга.

2. 2027 елның 1 январена Тукай муниципаль районының муниципаль эчке бурычы югары чиген нуль зурлыгы белән, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычның югары чиген нуль зурлыгы белән расларга.

3. 2028 елның 1 январена Тукай муниципаль районының муниципаль эчке бурычы югары чиген нуль зурлыгы белән, шул исәптән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының муниципаль гарантияләр буенча эчке бурычы югары чиген нуль зурлыгы белән расларга.

3 статья

1. Тукай муниципаль районы бюджетында 2025 елга фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 3 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

2. Тукай муниципаль районы бюджетында 2026 һәм 2027 еллар планы чорына фаразланган керемнәр күләмен әлеге карарга 4 кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 статья

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә Тукай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен расларга:

- 2025 елда 667,30 мең сум;
- 2026 елда 683,20 мең сум;
- 2027 елда 972,50 мең сум.

2. 2025 елда һәм 2026, 2027 еллар планы чорында Тукай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләр белән башкарыла дип билгеләргә.

5 статья

1. Тукай муниципаль районы чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 5 кушымта нигезендә;
- 2026 һәм 2027 еллар планы чорына әлеге карарга 6 кушымта нигезендә.

2. Тукай муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 7 кушымта нигезендә;
- 2026 һәм 2027 еллар планы чорына әлеге карарга 8 кушымта нигезендә.

3. Тукай муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре, бүлекчәләре буенча бүлүне расларга:

- 2025 елга әлеге карарга 9 кушымта нигезендә;
- 2026 һәм 2027 еллар планы чорына әлеге карарга 10 кушымта нигезендә.

4. Тукай муниципаль районы бюджетының гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2025 елга 28 222,60 мең сум, 2026 елга 28 986,40 мең сум, 2027 елга 29 910,70 мең сум күләмендә расларга.

6 статья

Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә Тукай муниципаль районы бюджетыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы 2 һәм 7 пункты нигезендә бирелә торган субсидияләр Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

7 статья

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен расларга:

- 2025 елга 82 163,60 мең сум күләмендә, әлеге карарга 11 кушымта нигезендә бүлеп;

- 2026 елга 79 779,30 мең сум күләмендә, әлеге карарга 12 кушымта нигезендә бүлеп;

- 2027 елга 82 320,10 мең сум күләмендә, әлеге карарга 13 кушымта нигезендә бүлеп.

8 статья

Тукай муниципаль районы Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2025 елга 55 417,40 мең сум, 2026 елга 57 443,50 мең сум, 2027 елга 59 230,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының гомуми кулланылыштагы юлларында юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга җибәрергә.

9 статья

Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга:

- 2025 елда 6 129,8мең сум;

- 2026 елда 6 704,3 мең сум;

- 20267 елда 6 944,9 мең сум күләмендә әлеге карарга 14 кушымта нигезендә бүлеп.

10 статья

Тукай муниципаль районы бюджетына авыл җирлекләре бюджетларыннан ай саен күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

- 2025-2027 елларга күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау чараларын тәэмин итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыруга ел саен 6 719,0 мең сум күләмендә әлеге карарга 15 кушымта нигезендә;

- җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча чараларны тәэмин итүгә 2025 елга 76 913,0

мең сум; 2026 елга 85 668,0 мең сум; 2027 елга 92 661,0 сум күләмендә, әлеге карарга 15 кушымта нигезендә бүлеп;

- муниципаль учреждениеләрне карап тотуга субсидияләр күләмен 2025 елга 83 632,0 мең сум; 2026 елга 92 387,0 мең сум; 2027 елга 99 380,0 мең сум күләмендә, әлеге карарга 16 кушымта нигезендә бүлеп.

11 статья

Тукай муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга:

- 2025 елда 769 829,79 мең сум;
- 2026 елда 813 285,24 мең сум;
- 2027 елда 874 568,78 мең сум күләмендә әлеге карарга 17-18 кушымта нигезендә бүлеп.

12 статья

2025 елда Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

13 статья

2025 елның 1 январена Тукай муниципаль районы бюджеты калдыклары Тукай муниципаль районы исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә (әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиеш) файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2025 елда, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

14 статья.

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендә административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә китерелгән зыянны түләтүдән, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны ирекле түләнә торган түләүләрдән әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына китерелгән зыянны мәҗбүри таләпләр бозылу нәтиҗәсендә алына торган салым булмаган керемнәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә вәкаләтле республика башкарма хакимияте органы тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының табигатьне саклау чаралары планы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән килешү буенча әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны ачыклау һәм бәяләүгә һәм (яисә) әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянны ликвидацияләүне оештыруга, хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә

тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү, табигать мохитен саклау һәм торгызу, табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны торгызу, экологик иминлекне тәэмин итү буенча башка чараларга юнәлдерелә дип билгеләргә.

15 статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Тукай районы территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Тукай муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

16 статья

Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан үз көченә керә.

17 статья

Әлеге карар Тукай муниципаль районы сайтында (tukay.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм «Якты юл» газетасында урнаштырыла.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет рәисе урынбасары Р.И. Закиров